

Үткән атнада жирле үзидарә хезмәткәрләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр.

Доньяда бар нәрсә дә үзгәрә, ә авыл хезмәте элеккечә барысына да кирәк. Сезнең жиргә хужаларча караш, хезмәтне ярату белән авыл хужалыгы тармагын – тормыш нигезен, авылның яшәү рәвешен, күптәнге традицияләрен саклыйсыз һәм үстерәсез. Әлеге бәйрәм конендә авылда яшәгән һәм жирдә эшләгән һәркемгә чын күнелдән рәхмәт әйтәбез. Хезмәтегезгә бирелгәнлек һәм тугрылык очен рәхмәт. Шундый хезмәткәрләр арасында лаеклы Фәрит Тахир улы Эртугановны атыйбыз.

Торбеево районы Сыркыды - Сургодь авыл жирлеге администрациясен 2013 елның мартыннан Фәрит Тахир улы Эртуганов житәкли. Анын житәкчелегендә авыл жирлеге Торбеево районының авыл территорияләре арасында үткәрелгән хезмәт ярышында берничә тапкыр жинүче иде. Ә сонгы елларда биредә үзгәрешләр дә шактый күп булды. 2018 елда Сургодь авыл жирлеге Лопатино авылы белән берләште һәм Фәрит Тахир улының мәшәкатьләре артты. Бүген биредә топ мәктәп, ике ФАП, ике КДЦ, ике авыл китапханәсе, почта, оч кибет эшли. 2019 елда Лопатино авылы Үзәк урамы буенча яна сүүткәргеч магистрале салынган.

Фәрит Тахир улы Эртуганов хезмәт соючәнлеге, үз-үзенә һәм хезмәттәшләренә таләпчәнлеге белән аерылып тора. Сыркыды авыл жирлеге коллективында да зур абруй казана. Хезмәт эшчәнлеге очен Мордовия Главасы һәм Мордовия Госсобраниесе Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде, Торбеево муниципаль районы хакимиятенен Рәхмәт хатлары һәм Мактау грамоталары белән күп тапкырлар бүләкләнгән хезмәткәр ул.

Якташлары хакына хезмәт куйган Тахир улы Фәритнен жинел булмаган эше яна

казанышлар һәм рәхмәтле як ташларыгызнын хормәте белән зурлансын. Киләчәктә дә хезмәт унышла рыгыздан макталыгыз.

Наилә НАСЫРОВА